**СОВЕТ ЧИРПОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422615, с. Чирпы,
ул. Заводская, д.22
тел: 2-91-45

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЧИРПЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422615, Чирпы авылы,
Завод урамы, 22 йорт,
тел: 2-91-45

---

**2026 елның «24» марты** **36 номер**

**КАРАР**

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Чирпы авыл җирлеге Советының 2023 елның 24 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Чирпы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәне раслау турында» 38 номерлы карарына үзгәреш кертү турында**

Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 28 декабрендәге 505-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасының муниципаль хезмәт турында Кодексының 8 матдәсенә үзгәреш кертү турында» Татарстан Республикасының 2025 елның 3 октябрендәге 66-ЗРТ номерлы Законына, «Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының 17 һәм 171 матдәләренә һәм Татарстан Республикасының муниципаль хезмәт турында Кодексының 18 һәм 19 матдәләренә үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасының 2026 елның 26 февралендәге 16-ЗРТ номерлы Законына таянып, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Чирпы авыл җирлеге Советы КАРАР ИТӘ:

1.Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Чирпы авыл җирлеге Советының 2023 елның 24 ноябрендәге 38 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Чирпы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1).8 нче бүлекнең 3 нче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен түбәндәге типик квалификация таләпләре билгеләнә:

1).һөнәри белем дәрәҗәсенә: югары, төп һәм әйдәп баручы вазыйфалар төркемнәре өчен югары белем булу, авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарындагы вазыйфалардан тыш; авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарындагы югары, төп һәм әйдәп баручы вазыйфалар төркемнәре өчен, шулай ук өлкән һәм кече вазыйфалар төркемнәре өчен югары белем яки урта һөнәри белем булу;

2). муниципаль хезмәт стажына яки белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына:

муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары буенча – ким дигәндә бер ел муниципаль хезмәт стажы яки белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча ким дигәндә ике ел эш стажы;»

«муниципаль хезмәтнең төп вазыйфалары буенча – ким дигәндә бер ел муниципаль хезмәт стажы яки белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажы

булу.»;

2) 20 нче бүлектә:

а) 1 нче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Муниципаль хезмәт вазыйфасын биләргә дәгъва кылучы граждан, муниципаль хезмәткәр яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль законда билгеләнгән очракларда әлеге Федераль законда күздә тотылган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти рәвештәге йөкләмәләр турындагы белешмәләрне тапшыралар. Күрсәтелгән белешмәләр Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре өчен «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль закон нигезендә керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти рәвештәге йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру өчен билгеләнгән тәртиптә, вакытларда һәм форма буенча тапшырыла.»;

б) 2 нче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Тиешле исемлеккә кертелгән муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче муниципаль хезмәткәр «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» Федераль закон) белән күздә тотылган чыгымнар турындагы белешмәләрне Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан мондый белешмәләрне тапшыру өчен билгеләнгән тәртиптә һәм форма буенча тапшырырга бурычлы.»;

в) 3 нче өлештә «2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы» дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

г) 4 нче өлештә «керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти рәвештәге йөкләмәләр турындагы» дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

д) 5 нче өлештә «керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти рәвештәге йөкләмәләр турындагы белешмәләрне» дигән сүзләрне «әлеге бүлек нигезендә муниципаль хезмәткәр тарафыннан тапшырыла торган белешмәләрне» дигән сүзләр белән алыштырырга;

е) 6 нчы өлештә «муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти рәвештәге йөкләмәләре турындагы белешмәләрне» дигән сүзләрне «әлеге бүлек нигезендә муниципаль хезмәткәр тарафыннан тапшырыла торган белешмәләрне» дигән сүзләр белән алыштырырга;

ж) 7 нче өлештә «үзенең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти рәвештәге йөкләмәләре турындагы, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти рәвештәге йөкләмәләре турындагы белешмәләрне» дигән сүзләрне ««Коррупциягә каршы тору турында» Федераль законда күздә тотылган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти рәвештәге йөкләмәләр турындагы белешмәләрне һәм «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» Федераль законда күздә тотылган чыгымнар турындагы белешмәләрне» дигән сүзләр белән алыштырырга;

з) 11 нче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«11. Контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләргә дәгъва кылучы гражданнар әлеге статьяның 1 нче өлешендә күрсәтелгән белешмәләрне

тапшыралар, мондый вазыйфаны биләүче зат әлеге бүлекнең 1 нче һәм 1.1 нче өлешләрендә күрсәтелгән белешмәләрне Татарстан Республикасы законында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Главасына (Рәисенә) тапшыра.»;

и) 12 нче өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

к) 14 нче өлештә «2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы» дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

3. 22 нче бүлекнең 3 нче өлешенең 10 нчы пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:«10. «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль законда күздә тотылган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти рәвештәге йөкләмәләр турында белешмәләр;».

2. Әлеге карарны Чирпы авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://laishevo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3.Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.

4.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Чирпы**
**авыл җирлеге Советы рәисе Л.М. Сатдинова**